| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘХМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

17 октябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Чуаш Мәнҗесе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 13 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Шоссе урамы, 25а адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Шоссе, Полевая урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 13 ноябрендә 0 9 сәгать 30 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Шоссе урамы, 25а адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Мәктәп, Үзәк урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Садовая урамы, 17 адресы буенча урнашкан йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Садовая, Дорожная, Бригада урамнарындагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2025 елның 13 октябрендә 11 сәгать 00 минутка Чуаш Мәнҗесе авылы, Лермонтов урамы, 18нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Чуаш Мәнҗесе авылының Лермонтов, Хәй Яһүдин исемендәге урамнардагы йортларда яшәүчеләр өчен Халык җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2026 елда Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗесе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Мәнҗесе авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгын Г.Н. Лизратова